| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ВВЕДЕНСКО-СЛОБОДСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЮГАРЫ ОСЛАН<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ<br>ВВЕДЕНСКИЙ БИСТӘСЕ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|


Ул. Центральная, д.55, с. Введенская Слобода, 422591

Үзәк ур., 55 нче йорт, Введенский Бистәсе авылы, 422591

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.


| ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР |
|---|---|
| 08.12.2020 | №189 |

с. Введенская Слобода

### Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлеге территориясендә пиротехника әйберләрен (фейерверк күрсәтү) куллануны тәртипкә салу чаралары турында

«Пиротехника әйберләрен тaратканда һәм кулланганда янгын куркынычсызлыгы таләпләрен раслау турында» 2009нчы елның 22нче декабрендәге 1052нче номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, «Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы белән, 2018нче елның 07нче сентябрендәге 57-245нче номерлы карар белән расланган, халыкның гомерен һәм сәламәтлеген яклау, муниципаль мөлкәткә, юридик һәм физик затларның мөлкәтенә зыян китерүне булдырмау максатларында:

Карар бирәм:

1. Введенский Бистәсе авыл җирлеге территориясендә 2020нче елның 20нче декабреннән 2021нче елның 10нчы гыйнварына кадәр янгынга каршы махсус режим урнаштырырга.
2. Янгынга каршы махсус режим гамәлдә булган чорда торак-коммуналь хуҗалык, авыл хуҗалыгы, кешеләр күп була торган объектлар чикләреннән 50 метр ераклыкта урнашкан территорияләрдә 1-3 класслы куркыныч пиротехника әйберләрен (бенгаль утларыннан һәм хлопушкалардан тыш) куллануны тыюны билгеләргә.
3. Введенский Бистәсе авыл җирлеге халкы тарафыннан Зөя елгасының яр буе территориясен пиротехник эшләнмәләр куллану урыны итеп билгеләргә.
4. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында халыкка җиткерергә һәм Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен үзем контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Введенский Бистәсе авыл җирлеге башлыгы Д. В. Морозов